МИНИСТЕРСТВО
ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул.Кремлевская, д.9, г.Казань, 420111

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН
МИНИСТРЛЫГЫ

Кремль ур., 9 нчы йорт, Казан шәһәре, 420111

Тел.: (843) 294-95-90, факс: (843) 292-93-51, e-mail: Minobr.Priemnaya@tatar.ru, сайт: mon.tatarstan.ru

____________________№________________

На №________________от________________

**Руководителям отделов (управлений) образования исполнительных комитетов муниципальных образований Республики Татарстан**

О проведении I межрегиональной
научно-практической конференции
«От школы - к науке, творчеству»

**Уважаемые руководители!**

В целях развития интеллектуального, художественного творчества учащихся, привития учащимся стремления к изучению татарского языка и татарской литературы, истории родного края, народного творчества Министерством образования и науки Республики Татарстан совместно с Управлением образования Исполнительного комитета Буинского муниципального района Республики Татарстан 28 марта 2018 года проводится I межрегиональная научно-практическая конференция «От школы - к науке, творчеству»

Для участия в Конференции приглашаются обучающиеся 1-11 классов общеобразовательных организаций Российской Федерации и Республики Татарстан. Заявку на участие и работы необходимо направить в срок до 19 марта 2018 года на электронный адрecdgamaletdinov@mail.ru с пометкой «Конференция» и указанием фамилии автора.

Командировочные расходы производятся за счет направляющей стороны.

Адрес проведения: Республика Татарстан, г. Буинск, ул. Роза Люксембург, д. 66 .

Место проведения: Муниципальное бюджетное общеобразовательное учреждение «Гимназия имени М.М. Вахитова города Буинска Республики Татарстан»

Контактный телефон: 8(84374) 3-14-64.

Приложение: на 5 л. в 1 экз.

**Первый заместитель министра** **И.Г.Хадиуллин**

Л.Т.Сахбиева
(843) 294 95 10


ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

«МӘКТӘПТӘН - ФӘНГӘ, ИҖАТКА»
ТӨБӘКАРА ФӘННИ-ГАМӘЛИ КОНФЕРЕНЦИЯ
НИГЕЗЛӘМӘСЕ

## 1. ГОМУМИ МӘГЪЛҮМАТ

Әлеге нигезләмә муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе «Татарстан Республикасы Буа шәһәре М.М. Вахитов исемендәге гимназия » базасында үткәрелә торган укучыларның «Мәктәптән - Фәнгә, Иҗатка» төбәкара фәнни-гамәли конференциясе (алга таба – Конференция) тәртибен билгели.

## 2. КОНФЕРЕНЦИЯНЕҢ МАКСАТ ҺӘМ БУРЫЧЛАРЫ

Конференция укучы балаларда татар әдәбиятын, сәнгатен, төбәкләр тарихын, татар халкының авыз иҗатын, мәдәниятен өйрәнүгә һәм каләм тибрәтүгә омтылышларын үстерү максатыннан үткәрелә.

Конференциянең бурычлары:

- хәзерге заман укучысының гомуми һәм коммуникатив культура дәрәҗәсен, социаль активлыгын үстерү һәм җәмгыятьтә үз урынын табарга өйрәтү;
- иҗади сәләтле һәм каләм тибрәтүче балаларны барлау, алга таба аларның сәләтләрен үстерүгә мөмкинлекләр тудыру, ярдәм итү;
- укучыларның иң яхшы казанышларын, белем бирү оешмаларының фәнни эшчәнлек белән шөгыльләнү тәҗрибәсен өйрәнү һәм пропагандалау;
- тикшеренү эше алып баручы коллективлар белән иҗади багланышлар формалаштыру, үзара аралашу оештыру;
- милли үзаң, үз милләтеңнең һәм төбәгеңнең тарихына, мәдәниятенә, гореф-гадәтләренә хөрмәт һәм мәхәббәт тәрбияләү;
- заман таләпләренә ия булган сыйфатлы белем бирүгә ирешү;

## 3.КОНФЕРЕНЦИЯНЕ ОЕШТЫРУЧЫЛАР

- Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы;
- Өстәмә профессиональ белем бирү дәүләт автоном учреждениесе «Татарстан Республикасы мәгарифне үстерү институты» ;
- Татарстан Республикасы Фәннәр Академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты;
- Татарстан Язучылар союзы берлеге;
- «Буа якташлыгы» җәмгыяте;
- Муниципаль бюджет учреждениесе «Буа муниципаль районы мәгариф идарәсе»;
- Муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе «Татарстан Республикасы Буа шәһәре М.М. Вахитов исемендәге гимназия».

## 4.КОНФЕРЕНЦИЯНЕ ҮТКӘРҮ ШАРТЛАРЫ ҺӘМ ТӘРТИБЕ

4.1. Конференциягә җибәрелгән фәнни-гамәли һәм иҗади эшләргә Татарстан Республикасы Фәннәр Академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре, Федераль университетының Лев Толстой исемендәге Филология һәм Мәдәниятара багланышлар институты мөгаллимнәре, Буа муниципаль районы мәгариф идарәсе методистлары, муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе «Татарстан Республикасы Буа шәһәре М.М. Вахитов исемендәге гимназия» укытучыларыннан торган экспертлар комиссиясе бәя бирә.

4.2. Конференциядә катнашу бушлай. Конференциягә җибәрелгән эшләр авторларга кире кайтарылмый.

4.3. Конференциядә катнашу тәртибе:

Конференциядә Нигезләмә шартлары буенча билгеләнгән вакытка кадәр гариза (Кушымта 1) белән татар телендә фәнни-гамәли һәм иҗади эшен җибәргән, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы белем бирү оешмаларында белем алучы 1-11нче сыйныф укучылары катнаша ала. Укучыларның фәнни-гамәли һәм иҗади эшләре һәр номинациядә түбәндәге яшь категорияләре буенча кабул ителә:

**1 нче төркем: 5 - 7 нче сыйныфлар;**

**2 нче төркем: 8 - 9 нче сыйныфлар;**

**3 нче төркем: 10 - 11 нче сыйныфлар.**

4.4 Һәр катнашучыдан билгеләнгән үрнәк буенча персональ мәгълүматларны куллануга ризалык турында белешмә тапшыру таләп ителә (Кушымта 2 –приложение к положению).

4.5 Конференция кысаларында түбәндәге секцияләр эшләячәк:

**1 нче юнәлеш ТАТАР ТЕЛЕ: «ТЕЛ КҮРКЕ - СҮЗ»**

- җанлы сөйләм теле үзенчәлекләре;
- халыкның фикер байлыгы;
- сүз тапкырлыгы һ.б..

**2 нче юнәлеш ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ: ӘДӘБИ-ЭСТЕТИК ЭЗЛӘНҮЛӘР**

***Фольклор белгече, филология фәннәре кандидаты, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Татарстан Республикасы Габдулла Тукай исемендәге премия лауреаты Ленар Җамалетдинов эшчәнлегенә багышлана:***

- төбәктә халык иҗатын өйрәнү тарихыннан;
- әдәбият һәм фольклор бәйләнеше;
- туган төбәк белән бәйле йолалар, җырлар, бәетләр: поэтикасы, жанрлары.

**3 нче юнәлеш БЕЗ ТАРИХТА ЭЗЛЕБЕЗ**

***Мәгърифәтче-язучы, уку китаплары төзүче, төбәк тарихын өйрәнүче, дин белгече Касыйм Бикколовның тууына 150 ел тулу уңаеннан***

- Касыйм Бикколов иҗатында белем һәм тәрбия мәсьәләләре чагылышы;
- Касыйм Бикколов повестьларында XX гасыр башы чынбарлыгы чагылышы;
- Авыллар тарихы, туган төбәктә булып узган тарихи вакыйгалар, тарихи шәхесләр, тарихи һәйкәлләр.

**4 нче юнәлеш МИНЕМ ТӘҮГЕ ИҖАДИ ЭШЕМ (башлангыч сыйныфларда укучылар өчен)**

- шигырь;
- проза әсәре;
- мәкалә һ.б.

4.6. Эшнең күләме 7 биттән артмаска тиеш. Эш төзәтүләрсез, А4 форматында (Word, шрифт Times New Roman – 14, интервал 1,5, уңнан – 1,5; сулдан- 2,5, астан – 2; өстән – 1,5) булырга тиеш. Тезисның күләме – 1 -2 басма бит.

4.7. Титул битенә белем бирү учреждениесенең тулы исеме, район, укучының фамилиясе, исеме, әтисенең исеме, сыйныфы, тема һәм укытучының фамилиясе, исеме, әтисенең исеме языла.

4.8. Кереш, йомгак, төп өлешнең аерым бүлекләре яңа биттән башлана. Кулланылган әдәбият исемлеге яңа юлдан алфавит тәртибендә языла.

Эзләнү эшләре түбәндәге таләпләргә җавап бирергә тиеш: укучының теманы ачып бирә алуы; композициянең тулылыгы, дәлилле, фәнни һәм иҗади фикерләү сәләтенә ия булуы; эшнең грамоталы, әдәби телдә язылган, мисалга китерелгән фактларның дөрес булуы шарт.

## 5. КОНФЕРЕНЦИЯ ЭШЛӘРЕН БӘЯЛӘҮГӘ ТАЛӘПЛӘР

5.1. Конференциягә җибәрелгән фәнни-гамәли эшләрне бәяләү критерийлары:

- тикшеренү эшендә билгеле булган нәтиҗәләр һәм фәнни фактларны куллану;
- кулланылган әдәбиятның сыйфаты;
- чыгыш ясаучының сөйләме, аралашу культурасы; максатны аңлау;
- проблеманың заманча халәтен белү (хәбәрдар булу);
- авторның мөстәкыйльлек дәрәҗәсе; сайланган теманың актуаль булуы;
- проблеманы чишүнең тирәнлеге, тулылыгы, үзенчәлекле ысулларны кулланган булуы;
- фәнни эштә логик эзлеклелек саклану;
- чыгышның композицион бөтенлеге, теманы ача һәм дәлилли белү дәрәҗәсе;
- чыгышны күрсәтмә материал белән баету;
- аралаша белү осталыгы.

5.2. Экспертлар һәр юнәлеш буенча бәя бирү критерийларын конкретлаштыру хокукына ия.

## 6. КОНФЕРЕНЦИЯНЕ ҮТКӘРҮ ВАКЫТЫ

6.1. Конференциядә катнашу өчен оештыру комитеты адресына (422430, Буа шәһәре, Р. Люксембург урамы, 66 нчы йорт, МБГББУ «Буа шәһәре М.М. Вахитов исемендәге гимназия») яки dgamaletdinov@mail.ru электрон әрҗәсенә «Конференция» тамгасы белән авторның фамилиясен күрсәтеп, 2018 нче елның 19 нчы февраленнән 19 нчы мартына кадәр гариза (үрнәктәгечә), чыгышның тезисы һәм эзләнү эше җибәрелә.

6.2. Конференция 2 этапта үтә.

6.3. **I этап – сайлап алу этабында (19 нче мартыннан - 2018 нче елның 23 нчы мартына кадәр)** жюри конференциягә җибәрелгән фәнни-гамәли һәм иҗади эшләрне карый һәм **II этапка** узучыларны билгели;

6.4. Нәтиҗә 2018 нче елның 23 нче мартыннан соң МБГББУ «Буа шәһәре М.М. Вахитов исемендәге гимназия» сайтына урнаштырылачак. Оештыру комитеты Конференция дипломантларына, Конференциядә катнашу өчен, чакыру хаты җибәрә (Һәр юнәлештән 15тән дә артык булмаган эш яклауга тәкъдим ителә).

6.5 Оештыру комитеты Конференция рекламасын Татарстан Республикасы мәгълүмат чараларына, интернет порталларына бирергә хокуклы.

6.6. **II этап – эшләрне яклау этабы 2018 нче елның 28 нче мартында** МБГБУ «Татарстан Республикасы Буа шәһәре М.М. Вахитов исемендәге гимназиясе»ндә үткәрелә.

6.7. Чыгыш ясау өчен укучыга 5-7 минут вакыт бирелә. Шул вакыт эчендә укучы төп фикерләрне кыска һәм төгәл итеп җиткерә белергә тиеш

6.8. Конференция аерым номинацияләрдә һәр яшь төркеме буенча иң яхшы фәнни-гамәли һәм иҗади эш авторларын дипломнар белән билгели (1, 2, 3 урыннар). Катнашучыларга шаһәдәтнамәләр электрон формада җибәрелә.

## 7. ӨСТӘМӘ МӘГЪЛҮМАТ

7.1. Оештыру комитетының адресы**:** 422430**,** Буа шәһәре Роза Люксембург урамы, 66 нчы йорт.

7.2. Белешмәләр өчен телефон: 8 (84374) 3 -14-64 ( Сафиуллина Эльвира Фәрит кызы); 8 -927- 0343557 (Юнысова Мәсгудә Мәсхут кызы).

E-mail: dgamaletdinov@mail.ru

**Кушымта 1**

**«Мәктәптән - фәнгә, иҗатка»**
**төбәкара фәнни-гамәли конференциясе өчен гариза үрнәге**

| | |
|---|---|
| Катнашучының (тулысы белән) фамилиясе, исеме, әтисенең исеме | |
| Уку йорты, сыйныф | |
| Фәнни-гамәли эшнең темасы | |
| Фәнни җитәкченең фамилиясе, исеме, әтисенең исеме | |
| Фәнни җитәкченең башкарган вазыйфасы | |
| Фәнни җитәкченең телефоны, эл. адресы | |
| Чыгыш ясау өчен кирәкле техник средстволар | |
| Секция | |

**Согласие на обработку персональных данных**

**Я, ______________________________________________________________**
*(ФИО родителя или законного представителя)*
паспорт _____ ____________, выдан ____________________________________
*(серия, номер)* *(когда, кем)*
*(в случае опекунства / попечительства указать реквизиты документа, на основании которого осуществляется опека или попечительство)*

______________________________________________________________________
*(адрес)*
даю согласие на обработку персональных данных моего ребенка

______________________________________________________________________
*(фамилия, имя, отчество ребенка)*

паспорт _____ _____________, выдан ________________________________
*(серия, номер)* *(когда, кем)*

______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
*(адрес)*

оператору Министерства образования и науки Республики Татарстан для участия в Конференции.

Перечень персональных данных, на обработку которых дается согласие: фамилия, имя, отчество, школа, класс, домашний адрес, дата рождения, телефон, адрес электронной почты, результаты участия в заключительном этапе Конференции.

Оператор имеет право на сбор, систематизацию, накопление, хранение, уточнение, использование, передачу персональных данных третьим лицам - образовательным организациям, органам управления образованием районов (городов), Министерству образования и науки РТ, Министерству образования РФ, иным юридическим и физическим лицам, отвечающим за организацию и проведение различных этапов конференции, обезличивание, блокирование, уничтожение персональных данных.

Данным заявлением разрешаю считать общедоступными, в том числе выставлять в сети Интернет, следующие персональные данные моего ребенка: фамилия, имя, класс, школа, результат заключительного этапа Конференции, а также публикацию в открытом доступе сканированной копии работы.

Обработка персональных данных осуществляется в соответствии с нормами Федерального закона Российской Федерации от 27 июля 2006 года № 152-ФЗ «О персональных данных».

Данное Согласие вступает в силу со дня его подписания и действует в течение 3-х лет.

______________________ ______________________
(личная подпись) (дата)

Лист согласования к документу № 1738/18 от 22.02.2018
Инициатор согласования: Сахбиева Л.Т Ведущий консультант отдела национального образования
Согласование инициировано: 22.02.2018 15:20

**Лист согласования** Тип согласования: **последовательное**

| N° | ФИО | Срок согласования | Результат согласования | Замечания |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Халиков И.И. | | Согласовано 22.02.2018 - 15:42 | - |
| 2 | Ахметзянова Л.М. | | Согласовано 22.02.2018 - 16:25 | - |
| 3 | Хадиуллин И.Г. | | Подписано 22.02.2018 - 18:05 | - |


ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН